**СОВЕТ САКЛОВ-БАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28.09.2016 №25

## Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Саклаубаш авыл җирлеге Уставының 11 ст., Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Бу мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:

"Саклаубаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 200 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүегез һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчалардан тыш, Сез 2017 елда үзара салым акчаларын кертүгә килешәсезме?:

- Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;
- Җирлек территориясендә физик культура һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар булдыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;
- Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү;

- җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру;
- җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктырту, территорияләрне яшелләндерү, урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләр кую, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тоту);
- ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту.

ӘЙЕ ЮК ".

2. Әлеге карар мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

Саклаубаш авыл җирлеге
Советы рәисе А.Ф.Мухаметгараев